**СОВЕТ ГОРОДА МАМАДЫШ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
**ул. М. Джалиля, 23/33, г. Мамадыш, 422190**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МАМАДЫШ ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ**
**М.Җәлил ур., 23/33, Мамадыш ш., 422190**

**тел.:(85563) 3-15-90, факс 3-24-00 ; e-mail:gorsovet.mamadysh@tatar.ru**

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 1-27** **от « 2 » октября 2018 г.**

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь, 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясының 2 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, "Җирле референдум турында» 2004 ел, 23 март, 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Мамадыш шәһәре җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре башкарма комитетының “Референдум уздыру инициативасы турында” 2018 елның 17 сентябрендә кабул ителгән 70 номерлы карары, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре Советының “Референдум уздыру инициативасы турында” 2018 елның 17 сентябрендә кабул ителгән 2-26 номерлы карары, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре Советының 18.10.2014 ел, № 1-26 карары (Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре Советының 2018 елның 17 сентябрендә кабул ителгән 1-26 нчы карары редакциясендә)белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре территориясендә гражданнарның үзара салымын җыю һәм куллану тәртибе турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре Советы К А Р А Р КАБУЛ ИТТЕ:

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдумны 2018 елның 18 ноябренә билгеләргә.

Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында катнашканнарның тол хатыннары, тыл хезмәтчәннәреннән кала, шулай ук

үзара салым акчасының 50% ташламасы белән көндезге бүлектә белем алучы студентлар файдалана, 2019 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

1). 1.Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр кысаларында җирлек чикләрендә халыкны электр, җылылык, газ һәм су белән тәэмин итүне, су чыгаруны, ягулык белән тәэмин итүне оештыру;

- Мамадыш шәһәре территориясендә электр линияләрен төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау.

2. Җирлектә яшәүче халыкның бергә җыелып ял итүе өчен шартлар тудыру һәм халыкның җыелып ял итү урыннарын төзекләндерү, гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр буе полосаларына ирекле керә алуын тәэмин итү;

- Мамадыш шәһәре территориясендә пляжны төзекләндерүне оештыру.

« ӘЙЕ » « ЮК »

3.Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен үз контролемә алам.

Шәһәр башлыгы,
Мамадыш муниципаль районының
Мамадыш шәһәре Советы рәисе А.П.Иванов